ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 10.07.2015 г. Казань № 10-16/кс

***2015-2018 елларга***
***2015 – 2018 елларга «Балык бистәсе торак комуналь сервис» ҖЧҖе тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында***

«Коммуналь комплекс оешмаларының тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ санлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя кую нигезләре һәм тарифларны, өстәлмәләрне һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 санлы карарына, «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә тарифларны һәм өстәлмәләрне исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2011 елның 15 февралендәге 47 санлы Россия Федерациясенең региональ үсеш министрлыгы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР бирә:

1. «Балык бистәсе торак комуналь сервис» ҖЧҖе тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны, календарь чорларына бүлеп, әлеге карарның 1 нче кушымтасындагыча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 июненнән 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендә әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән тарифларның гамәлдә булу чорына «Балык бистәсе торак комуналь сервис» ҖЧҖе җитештерү программасының төп күрсәткечләрен әлеге карарның 2 кушымтасына нигезләнеп килештерергә.

4. «Балык бистәсе торак комуналь сервис» ҖЧҖә билгеләнгән вакытка, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 30 декабрендәге 1140 санлы карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

5. Әлеге карарда билгеләнгән каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийлар системасын урнаштыру турында» 2015 елның 24 февралендәге 44а санлы боерыгы белән расланган коммуналь комплекс оешмалары товарларыннан һәм хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийларына туры килә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисе вазифаларын башкаручу Л.П.Борисова

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
1 нче кушымта
10.07.2015 № 10-16/кс

2015 – 2018 елларга
«Балык бистәсе торак комуналь сервис» ҖЧҖе тарафыннан билгеле бер календарь чорларына
каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № п/п | Коммуналь комплекс оешмасы, муниципаль берәмлек атамасы | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар сум/куб.м | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2015 елның 1 сентябереннән 31 декабренә кадәр | 2016 елның 1 гыйнварыннан 30 июненә кадәр | 2016 елның 1 июленнән 31 декабренә кадәр | 2017 елның 1 гыйнварыннан 30 июненә кадәр | 2017 елның 1 июленнән 31 декабренә кадәр | 2018 елның 1 гыйнва-рыннан 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән 31 декабренә кадәр |
| | Балык бистәсе муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Балык бистәсе торак коммуналь сервис»*ҖЧҖ | 118,94 | 118,94 | 128,14 | 126,86 | 126,86 | 123,80 | 123,80 |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
2 нче кушымта
10.07.2015 № 10-16/кс

## Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендә «Балык бистәсе торак комуналь сервис» ҖЧҖе җитештерү программасының төп күрсәткечләре

| № п/п | Комму-наль ком-плекс оешмасы атамасы | 2015 елның 1 сентябереннән 31 декабренә кадәр | | | | | 2016 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр | | | | | 2017 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр года | | | | | 2017 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр года | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре, | | | | Кирәк-ле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре, | | | | Кирәк-ле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре | | | | Кирәк-ле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре | | | | Кирәк-ле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) |
| | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызлан-дыру һәм күмү күләме, мең куб.м шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызлан-дыру һәм күмү күләме мең куб.м, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызлан-дыру һәм күмү күләме мең куб.м, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызлан-дыру һәм күмү күләме мең куб.м, шул исәптән: | | | | |
| | | Бар-лы-гы | Ха-лык | Бюджет кулла-нучыла-ры | Башка кулла-нучы-лар | | Бар-лыгы | Ха-лык | Бюджет кулла-нучыла-ры | Башка кулла-нучы-лар | | Бар-лыгы | Ха-лык | Бюджет кулла-нучыла-ры | Башка кулла-нучы-лар | | Бар-лыгы | Халык | Бюджет кулла-нучыла-ры | Башка кулла-нучы-лар | |
| 1 | «Балык бистәсе торак коммуналь сервис» ҖЧҖ * | 10,7 | 8,3 | 1,7 | 0,7 | 1272,68 | 10,7 | 8,3 | 1,7 | 0,7 | 1321,87 | 10,7 | 8,3 | 1,7 | 0,7 | 1357,36 | 10,7 | 8,3 | 1,7 | 0,7 | 1324,70 |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге